**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СУЫКСУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Суыксу авылы, Мәктәп ур, 9А

**СОВЕТ СУКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422729, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Суксу, ул. Школьная, 9А

тел./факс 8(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**
**13 декабрь 2019 ел** **№ 177**

**Суыксу авыл җирлеге Советының “Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешүләр төзү тәртибен раслау турында”, 2019 елның 18 ноябрендәге 169 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы 4 бүлеге, “Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы белән эш йөртеп, Суыксу авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Суыксу авыл җирлеге Советының “Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнары белән вәкаләтләрнең бер өлешен тапшыру (кабул итү) турында килешүләр төзү тәртибен раслау турында”, 2019 елның 18 ноябрендәге 169 номерлы карары кушымтасындагы 5.2 пунктында “аңа имза куйган вакыттан” сүзләрен “рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң)” сүзләре белән алмаштырырга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән соң) үз көченә керә.
4. Үтәлешне контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
авыл җирлеге башлыгы Р.С.Низамиев